РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ ШИКШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422053, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шикши, ул. Школьная, 4
тел. (84362) 46-1-35

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422053, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шекше авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт
тел. (84362) 46-1-35

e-mail: Shik.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.10.2019 №22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Шекше авыл җирлеге составына керүче торак
пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек
тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге уставын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 24.09.2018 елда №15 белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shikshi бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шекше авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Хайртдинов